ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«18» декабрь 2020 ел **№ 1035**

**Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы "Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, торак йортны бакча йорты, бакча йортын торак йорт дип тану турында Нигезләмә" карары нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия составын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 15 декабрендәге 1329 номерлы “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында” карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
18.12. 2020 ел, №1035
карарына кушымта

**Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомстоволара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Р.Р. | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Гәрәев М.Р. | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы мөдире, комиссия секретаре. |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Касыймов Р.Ф. | - комиссия рәисе урынбасары, Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әгълиев И.К. | - «Арча муниципаль районы идарәче компаниясе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Гатиятова Е.Н. | - «Татарстан Республикасы техник инвентаризация бюросы» АҖ бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Арефьева Е.Н. | - Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Салкова Э.В. | - Арча, Биектау, Әтнә, Балтач районнары буенча баш дәүләт санитария табибы (килешү буенча). |

Искәрмә: Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл иткәндә комиссия составына торак бина урнашкан территориядәге авыл җирлекләре башлыклары кертелә.